Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахча авыл җирлеге составына керүче Уракчы авыл җирлегендә гражданнар җыены

# КАРАРЫ

18 ноябрь 2022 ел № 2

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Уракчы авыл җирлеге составына керүче Мельничный Пүчинкәсе авылындагы гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде**:

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахча авыл җирлегенең Уракчы авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, беренче торкем инвалидлардан мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре), 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;

2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:

-торак пунктлар чикләрендә урамнарны яктырту челтәрләрен тоту (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам утларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү;

- авыл җирлеге чикләрендә су белән тәэмин итү системасын тәртиптә тоту (суэтем башняларына тирәнлек насослары сатып алу өчен);

- торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау;

-авыл җирлеге чикләрендә кышкы юлларны карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту-килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- авыл җирлеге территориясен җәй көне чабу (ягулык-майлау материаллары, трактор һәм аларга комплектлаучылар өчен асылмалы җиһазлар, запас частьләр сатып алу , килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- зиратларны төзекләндерү һәм карап тоту (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахча авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Уракчы авылы, Совет урамы, 36Айорт; Мельничный Починок авылы, Киров урамы, 20Б йорты Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Уракчы авыл җирлеге башлыгы: Гәрәев Ф.М.